МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

01.04.2024 Казан ш. № 185-пр

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 05.09.2023 № 625-пр боерыгы белән расланган Россия Федерациясе гражданнарына үзләре биләп торган, «Республика мөлкәт казнасы» дәүләт бюджет учреждениесенә оператив идарә хокукында беркетелгән торакларны милек итеп тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм “Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү хакында” Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү турында” 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертелү сәбәпле боерам:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Россия Федерациясе гражданнарына үзләре биләп торган, «Республика мөлкәт казнасы» дәүләт бюджет учреждениесенә оператив идарә хокукында беркетелгән торакларны милек итеп тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында” 05.09.2023 № 625-пр боерыгы белән расланган Россия Федерациясе гражданнарына үзләре биләп

торган, «Республика мөлкәт казнасы» дәүләт бюджет учреждениесенә оператив идарә хокукында беркетелгән торакларны милек итеп тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлекнең 2.6.2 пунктында:

5 подпунктында «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән калган балаларны торак белән тәэмин итү турында һәм “Татарстан Республикасы халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында” Татарстан Республикасы Законынаның 8 статьясына үзгәрешләр кертү турында” сүзләрен “Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән калган балаларның, алар исәбендәге затларның торакка хокукларын тормышка ашыру турында” сүзләре белән алыштырырга;

6 подпунктында «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән калган балаларны торак белән тәэмин итү турында һәм “Татарстан Республикасы халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында” Татарстан Республикасы Законынаның 8 статьясына үзгәрешләр кертү турында” сүзләрен “Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән калган балаларның, алар исәбендәге затларның торакка хокукларын тормышка ашыру турында” сүзләре белән алыштырырга;

2. Министр урынбасарларына, идарә башлыкларына хезмәткәрләрне әлеге боерык белән таныштыруны оештырырга һәм аның тайпылышсыз үтәлешен тәэмин итәргә

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**